РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

24 июль 2023 ел №196

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 24 апрелендәге №149 Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җирле үзидарәнең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларының, сайлап куела торган вазыйфаи затларының, муниципаль берәмлекләрдәге контроль-исәп органнары рәисләренең, рәисләре урынбасарларының, аудиторларының, Татарстан Республикасындагы муниципаль хезмәткәрләрнең хезмәте өчен түләү чыгымнарын формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 28 мартындагы №182 карары, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. «Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатларның, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи затларының, контроль-хисап органнары рәисләренең, Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт хакына чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында» 2018 елның 24 апрелендәге № 149 Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы карарына (район Советының 2020 елның 29 октябрендәге №8, 2022 елның 27 октябрендәге №140, 2022 елның 28 декабрендәге № 156 карары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карарның 8 нче кушымтасында:

- 4 нче пунктны яңа редакциядә бәян итәргә: «4. Премияләр күләме абсолют күләмдә (рубльдә), шулай ук муниципаль хезмәтнең биләнә торган вазифасы буенча акчалата эчтәлеккә яки вазифа окладларына тапкырлыкта билгеләнә ала. Шул ук вакытта премия максималь күләме белән чикләнми, билгеләнгән хезмәт хакы фонды чикләрендә. Премияләр агымдагы сметада хезмәткә түләү фонды экономиясе булганда, финанс елына бюджетта расланган план күрсәткечләреннән артык бюджетны үтәгәндә фактик алынган керемнәр һәм агымдагы финанс елы башына барлыкка килгән район бюджеты счетындагы калган акчалар булганда, шулай ук Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы бюджетының финанс-икътисадый торышыннан чыгып түләнә».

- түбәндәге эчтәлектәге 6 нчы пункт белән тулыландырырга: «6. Эш бирүче карары буенча аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премия түбәндәге очракларда түләнми:

- җирле үзидарә органнарының норматив актлары белән расланган нәтиҗәлелек күрсәткечләрен үтәмәү;

- 3 һәм аннан да күбрәк документны (мөрәҗәгатьләрне, хатларны) карау срогы бозылган очракта;

- район Башлыгының, җирле үзидарә органы җитәкчесенең квартал дәвамында 1 һәм аннан да күбрәк протокол йөкләмәләрен үтәмәү яки тиешенчә үтәмәү;

- милекне юк итүгә китермәгән муниципаль милеккә матди зыян китерү;

- шелтә рәвешендә дисциплинар җәза булу;

- өченче затларга вазифа бурычларын үтәгәндә билгеле булган хезмәт мәгълүматларын ачу;

- муниципаль хезмәт узу белән бәйле чикләүләрне һәм тыюларны, хезмәт тәртибе йөкләмәләрен һәм кагыйдәләрен, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу таләпләрен үтәмәү, коррупциягә каршы тору максатларында билгеләнгән бурычларны үтәмәү;

- вазифа бурычларын үтәмәү яки тиешенчә үтәмәү сәбәпле».

1.2. Түбәндәге эчтәлектәге 7 пункт белән тулыландырырга: «7. Билгеле бер чорда билгеләнгән аеруча мөһим һәм катлаулы биремнәрне үтәгән өчен премия, муниципаль хезмәткәрнең еллык түләүле ялда, тиешле еллар эшләгән өчен өстәмә түләүле ялда, нормалаштырылмаган эш көне өчен өстәмә түләүле ялда, хезмәт командировкасында һәм эш бирүче инициативасы буенча өстәмә һөнәри белем алуда булган вакытын исәпкә алып, гамәлдә кулланылган вакыт өчен исәпләнә һәм түләнә.

Премия сынау срогын уңышлы узган муниципаль хезмәткәрләргә, сынау срогын үткән вакытны һәм эш нәтиҗәләрен исәпкә алып түләнә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башлыгы урынбасарына, Совет рәисе урынбасарына һәм Совет аппараты җитәкчесенә йөкләргә.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов